**Яр Чаллы шәһәре Хакиме**
**карары**

**№М 254**
**17.06.2022**

Шәһәр Хакименең «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар, шулай ук Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирү турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2014 елның 21 ноябрендәге М 692 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 1 апрелендәге 90-ФЗ номерлы Федераль закон, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Шәһәр Хакименең «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар, шулай ук Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирү турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2014 елның 21 ноябрендәге М 692 номерлы карарына (Шәһәр Хакименең 2015 елның 24 февралендәге М 58 номерлы, 2016 елның 1 февралендәге М 34 номерлы, 2018 елның 29 июнендәге М 293 номерлы, 2021 елның 14 маендагы М 186 номерлы, 2022 елның 14 мартындагы М 94 номерлы карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт

вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар, шулай ук Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирү турында нигезләмәдә:

- 6 пунктның «в» пунктчасында «акцияләр» сүзен төшереп калдырырга;
- 13 пунктта «акцияләр» сүзен төшереп калдырырга;

2) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнарында вазыйфалар исемлегенә кертелгән муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүче муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан бирелгән керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турындагы мәгълүматларны, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турындагы мәгълүматны Интернет челтәрендә www.nabchelny.ru Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтына урнаштыру турында һәм бастырып чыгару өчен әлеге мәгълүматларны массакүләм мәгълүмат чараларына бирү турында нигезләмәнең 3 пунктындагы 4 пунктчасында «акцияләр» сүзен төшереп калдырырга;

3) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнарында вазыйфалар исемлегенә кертелгән муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүче муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан бирелгән керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турындагы мәгълүматларны, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турындагы мәгълүматларны Интернет челтәрендә www.nabchelny.ru Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтына урнаштыру турында һәм бастырып чыгару өчен әлеге мәгълүматларны массакүләм мәгълүмат чараларына бирү турында нигезләмәгә кушымтада «акцияләр» сүзен төшереп калдырырга.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны муниципаль берәмлек Башлыгы урынбасары И.А. Сәгыйдуллинага, Башкарма комитет Җитәкчесе Ф.Ш. Салаховка, Контроль-хисап палатасы рәисе Т.В. Шливега йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев